Ә менә бабамның тагын бертуган абыйсы Әнвәрбик абый атасы исемен фамилия итеп ала. Ул – Мөхәммәтҗанов. Алар Карл Маркс урамында яши. Ике кызлары Лилия, Ләйлә Кукмарада яшиләр. Ә без дус гаилә булып әти-әнием һәм энем белән Яшьләр урамында яшибез.

Мин шушы нәселдән булуым белән чиксез горурланам. Очраклы гына безнең нәсел турында Сибгат абый мондый юллар калдырмагандыр:

> Безнең буын – озын чылбыр ул.
> Кырлар буйлап узган озын юлдыр ул
> Озын чылбыр. Бик күп боҗралар.
> Ул боҗралар – бар да без алар.

## СИБГАТ ХӘКИМ – ТУГАН ЯК ҖЫРЧЫСЫ
### (Дәрес эшкәртмәсе)

***Т.Ә. Сабитова,***
*Арча районы Шушмабаш мәктәбе*

*Максат:* шагыйрьнең тормыш юлы белән таныштыру, иҗатына күзәтү ясау. «Әнкәй» шигырен уку һәм анализлау; укучыларда әти-әниләргә, туган җиргә карата мәхәббәт, җылы хисләр тудыру.

*Материал:* дәреслек, портреты, китап күргәзмәсе, рәсемнәр, компьютер, проектор, магнитофон, әдәби журнал, аның турында әйткән сүзләр, ромашка.

**Дәрес барышы**

Актуальләштерү.

1. Дәреснең темасы белән таныштыру.

*2.* С. Хәким турында нәрсә беләсез?

– Укучылар! Бүген без сезнең белән С. Хәкимнең, тормыш юлы, иҗаты белән танышабыз. Аның тормыш юлын

өйрәнү өчен телдән журнал чыгарырбыз. Быел 4 декабрьдә Татарстанның халык шагыйре, Татарстанның Тукай исемендәге дәүләт, РСФСРның М. Горький исемендәге премияләре лауреаты С. Хәкимнең тууына 100 ел тулды. Аның турындагы журналыбызның беренче битен ачабыз.

*1 бит*. Балачак мизгелләре.

Эпиграф:

Яратам мин авыл кешесенең
Күңелле итеп әкият сөйләвен.
Әкият кебек матур Казан арты –
Балачагым, туган җирләрем.

Сибгат Таҗи улы Хәким Арча районы Күлле-Киме авылында крестьян гаиләсендә туган, 7 сыйныфны тәмамлагач, мәктәптә пионервожатый булып эшли *(Проектордан рәсемнәр күрсәтелә).* (Шагыйрьнең, әтисе Таҗи абзый балта эшена бик оста булган. Әнисен «туры Газзә» дип йөрткәннәр, чөнки ул туры сүзле, гадел булган. Аның бала чагы бик авыр елларга туры килгән.

Сибгат Хәким болай дип искә ала. *«Дәреслек, 126 бит-127).* Мари ягы – урманлы як *(картадан күрсәтелә).* Анда яңгыр күбрәк ява. 1921 елгы ачлыкта без шул мари авылларына сыендык. Шактый бәрәңге ташыдык без ул яктан, – ди ул. Ул ихлас күңелдән халыклар дуслыгын хуплый, зурлый. Аның, мари халкына багышланган шигырьләре дә байтак. «Мари карты Филипп», «Мари кызы Улина» һ. б. *(Тактада ромашка рәсеме ясала башлый).*

Әтисе улын саклап кала алса да, үзе ул ачлык елында *(1921)* вафат була.

*2 бит.* Иҗади эзләнүләр язар өчен илһам эзлә, диләр,
Урын әзлә, диләр, ямьлерәк.
Никтер минем шигъри хисләремә
Арышларның исе тәмлерәк!

1931 елда Казанга килә. Рабфакка укырга керә. КДГПИ ның татар теле, әдәбияты бүлеген тәмамлый *(студент).*

1937 елда китап нәшриятында редактор, әдәби хезмәткәр булып эшли. Беренче иҗади юллар туган ягына багышлана «Зөбәрҗәт, алтыннарың», «Кышкы салкын иде», «Яратам мин», «Пар ат», «Юксыну». *(82 бит)...*

Әзләмә син диңгез төбеннән
Һич табалмый торган энҗене,
Тап иптәшең, булыр кешене,
Гади бер дус үзең, ишене. *(1939)*
Олавымда килеш күзәттем мин
Сызылып килгән таңның яктысын,
Туган җирем, сиңа бирермен мин
Хисләремнең иң-иң татлысын *(1940)*
... Пошкырыплар атлар уза юлдан,
Олау тавышы җәелә кырларга.
Яратам мин кышкы озын төндә
Юлчыларның җырын тыңларга. *(1938)*

*3 бит.* Дәхшәтле фронт юллары.

Оныгылмаслык итеп кыйналдык без,
Егетләре Казан артының.
Тап төшмәсен барыр юлларына,
Намусына татар халкының.

С. Хәким Мөршидә белән 1938 елда өйләнешәләр. Х. Туфан аларның, туена багышлап шигырь дә яза *(15 биттәге истәлек)* 1941 елда гаиләгә шатлык өстәлә, уллары Рөстәм туа. Ләкин бәхетле тормыш озак дәвам итми. Сугыш башлана...

Сибгат абый 1941 нче елның июнендә үк армиягә алына. Хатынын яшь баласы булган өчен генә фронтка алмыйлар. *(«Шәфкать туташы»,* 7 бит)

Башта С. Хәким взвод, рота командиры була. Ул сугышның башыннан ахырына кадәр пехота офицеры була. Җилкәсендә авыр әйберләр күтәреп йөргәнлектән, ике аягында да кан та-

мырлары шешкән... Үпкә, бавыр, ашказаны, эчәкләренә салкын тигән – бар да авырталар. Шулкадар авыру булуына карамастан, сугыш беткәч бер ел хәрби газетада эшләткәннәр. 1946 елның язында гына кайта. 75 кг булып киткән С. Хәким 45 кг булып кайта.

... Кайда гына йөрсә дә, ул туган Жирен онытмый, сагына.

Йөгерә-йөгерә чыктым урамга мин.
Ял итәргә кергән өемнән;
Искә төшереп безне эзләп килгән.
Бу матур көй – туган җиремнән, – дип яза ул 1944 елда.

1947 елда улы Рафаэль туа. *(Аның турында проектордан рәсемнәр күрсәтелә)* 1947 елда «Әй язмыш, язмыш» языла. *(җыр тыңлана)*

*4 бит.* Туган як – мәңгелек моңым.
Туган жир, ахры, күңелемнән.
Кайчан да китмәс.
Ул хакта җырлап, сөйләп тә,
Сүзләрем бетмәс.

Аның иҗатында туган як, әниләр темасы зур урын алып тора. Кайда гына йөрсә дә, ул үзенең туган төбәген беркайчан исеннән чыгармаган.

– С. Хәкимнең үзенең тавышын тыңлау. «Сусау» шигыре.

– Укучылар туган җир, авылга багышланган шигырьләрен сәнгатьле итеп сөйлиләр.

Күңелеңдә, әнкәй, туган як
Бербөтенгә әверелә,
Колак салам шул илаһи
Бөек көчнең гомеренә.
Коенып үскән су буе,
Шылт та итми як-якта
Яшәргә риза мин монда
Әйләнеп бер яфракка.

Бу тургайлар, әйе, бу тургайлар
Басуларга мине дәште гел.
Тургай моңы кебек шул кырларда
Чыңлап узды минем яшьлегем.
Тәрәзәләр ачып бер сызгырдым
Чапкан печәннәрем кипсен дип.
Покосларым буйлап сагышларым
Сезнең якка таба китсен дип.

*5 бит.* Әниләр – иң кадерле кешеләр. С. Хәким иҗатында әниләргә бик зур урын бирелгән. Без бүген «Әнкәй» шигыренә тукталабыз. Дисктан шигырь тыңлана *(артист башкаруында)*. Берничә укучы укый.

Әни – җирдә иң, газиз якын кеше. Чөнки ул сине тудырган, күкрәк сөтен имезгән, жыр көйләп бишектә тирбәткән, беренче елмаюын күреп куанган, туган телне өйрәткән, халык моңын күңеленә сеңдергән. Әниләрнең сиңа кылган изгелеген санап бетерү мөмкинме соң?

Кешегә гомере буена әти-әнисе кирәк. Аларның кайгыртучан карашы, җылы сүзләре, акыллы киңәшләре җанга рәхәтлек бирә. С. Хәким дә әти-әнисенә гомере буе рәхмәтле булып яшәгән. Аның әнисенә багышланган шигырьләрендә күпме ихласлылык, рәхмәт хисе!

Урта гасырлар татар шагыйре М. Колый: «Ата-ананы хөрмәт иткән, аларга хезмәт күрсәткән, күңелләрен хуш кылган уллар-кызлар – Аллаһы Тәгаләненең, дустыдыр», – дигән.

Нәтиҗә ясала. Иҗаты күпкырлы. Ләкин туган җир, әниләр темасына гомере буе мөрәҗәгать иткән.

Йомгаклау. Өйгә эш.

«Әнкәй»шигырен ятларга, С. Хәкимнен биографиясен сөйләргә әзерләнергә.

Чыганак: Сагына Киме, сагына бөтен илем сөекле улын – халык җырчысын : татар теле һ. әдәбияты укытучылары, студентлар өчен метод. кулланма / төз. : З. Н. Җиһаншина ; ф. мөх-ре: Р. Р. Харрасова. – Казан : ГБУ «Республиканский центр мониторинга качества образования», 2013. – 148 б.